АКЧА САНАГАНДА
Икътисад коллегиясендә матди хәлебез турында сөйләделәр

> 2

ИЛ УЛЛАРЫ
Февраль – Татарстанга данлыклы кешеләрен бүләк иткән ай

> 3

ЯЗУЧЫ СҮЗЕ
«Барысы да оҗмах эзләп китә: яшьләр – шәһәргә, карт-коры – теге дөньяга»

> 4

САГЫНДЫРГАН КИЧЛӘР
Казанда Чаллы театры гастроле булды

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 25 (28992) | Шимбә | 18 февраль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Лилия ГЫЙМАЗОВА

КЕЛӘМНЕҢ КЫЗГАН ЧАГЫ

КАЗАННЫҢ «АК БАРС» КӨРӘШ САРАЕНДА МУСА ҖӘЛИЛ ТУРНИРЫ ГӨРЛИ

Герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган көрәш турнирының 60 нчы сәхифәсен Казанда язабыз. Батыр исемен кемнәр алыр да, иң көчлеләр булып кемнәр танылыр? Бу сорауга җавапны шимбә белербез. Ә әлегә турнирның беренче көненнән репортаж тәкъдим итәбез.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Җиңеп яшик!

60 нчы турнирның ачылыш тантанасы үзе бер бәйрәм булды. Тинчурин театры артистлары тарафыннан әзерләнгән театральләштерелгән тамашада газетабыз тарихының сәхифәләре батырлык үрнәкләре белән үрелеп барды. Илсөя Бәдретдинова, Вил Усманов, «Болгар кызлары»ның чыгышлары көрәш бәйрәменә дәрт һәм ямь өстәде.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, республиканың Көрәш федерациясе президиумы рәисе Марат Әхмәтов ачылыш тантанасында әлеге турнирның көрәш тарихында ярты гасырдан артык үз абруен саклавын әйтте.

– Ихлас күңелдән барчагызны да спорт һәм сәнгать бәйрәме белән котлыйм! Герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә узучы көрәш бәйгесе – инде 60 ел дәвамында «Ватаным Татарстан» газетасы һәм безнең федерация белән берлектә оештырылып килгән иң дәрәҗәле, иң абруйлы турнир. 350дән артык көрәшче, 45 команда. Башка бер спорт төрендә дә мондый дәрәҗәдәге ярышлар узмый. Бүген без, горурланып: «Без – көрәшле халык, без – көрәшче халык!» – дип әйтә алабыз. Бүген Ватаныбыз язмышы өчен безнең көрәшле һәм көрәшче булуыбыз, җиңеп яшәвебез аеруча зур әһәмияткә ия, – диде ул. – Ике көн дәвамында милләтебезнең асыл егетләре матур көрәш күрсәтәчәк. Бүген безгә татар көрәшенең легендаларын күрү бәхете дә елмайды. Әлеге истәлекле бәйгедә уникешәр, унар тапкыр җиңү яулаган каһарман көрәшчеләребез, яшь буыныбыз өчен үрнәк ир-егетләребез алар. Көрәшеп яшик, җиңеп яшик!

Тантанада Россиянең Спортчылар советы президенты, иректә көрәш буенча Олимпия чемпионы Давид Мусульбес та катнашты.

– Татарстан – гаҗәеп мәдәнияте белән түгел, искиткеч көрәшү стиле белән дә дан казанган төбәк. Илебездә яшәүче халыкларның һәм мәдәниятләрнең күптөрле булуы төрле көрәш стильләре мәктәбен саклап, яшь буынга тапшырырга ярдәм итте, – диде ул. – Көрәш ветераннарын зурлавыгыз өчен аерым рәхмәтемне әйтәсем килә. Яшь буын аларны күреп үсәргә тиеш. Мондый чаралар булып торсын!

Дәрәҗәне төшермәскә! Ничә буын көрәшче өчен кадерле булган әлеге турнирны оештырган вакытта без һәрвакыт шуңа омтылабыз. Быелгы юбилей турниры уңаеннан, татар көрәшенең күркәм сәхифәләрен барлап, махсус чыгарылыш әзерләдек. «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире урынбасары Илнар Хөснуллин сүзләре белән әйтсәк, быелгы турнир, чын мәгънәсендә, тарихи әһәмияткә ия.

Батырларга бүләкләр

I урынга – **50 мең**, II урын өчен – **40 мең**, ике III урынга **30ар мең** сум күләмендә акча бирәчәкләр. Финал ярышында иң яхшы көрәш алымнары күрсәткән егеткә Ильяс Галимов исемендәге **30 мең** сумлык махсус премия дә тапшырылачак.

– Бүген без Муса Җәлил истәлегенә узучы турнирның гына түгел, татар көрәшенең һәм, гомумән, татар халкының тарихын барлыйбыз. Әлеге тарихны барлаганда, көрәш келәмендә зур җиңүләргә ирешкән батырларның тормышта да югалып калмавын, яшәешнең төрле өлкәләрендә уңышка ирешүен күрәбез. Димәк, көрәш – безнең яшәү рәвешебез дә. Бүген келәм тотучы яшь көрәшчеләребезгә дә батырлыкларын югалтмыйча, татар халкының горур уллары булуларын телибез. Ярышлар гадел һәм имгәнүләрсез генә узсын! – дип теләде ул.

Ахыры 3 нче биттә >

Көрәш бәйгесен ачу тантанасында 2022 елның иң яхшы көрәшчеләрен, тренерларын, хөкемдарларын һәм журналистларын бүләкләделәр.

Иң яхшы көрәшчеләр – *Радик Сәлахов, Алексей Абрамов һәм Илмир Төхвәтуллин.*

Яшьләр белән эшләүче иң яхшы тренерлар – *Әлмәттән Руслан Нургалиев, Актаныштан Илфир Әнвәров һәм Казаннан Николай Крылов.*

Өлкәннәр белән эшләүче иң яхшы тренерлар – *Чаллыдан Илнур Хәйбуллин, Әлмәттән Ильяс Билалов һәм Казаннан Җәүдәт Хөсәенов.*

Районнар арасында көрәш буенча иң яхшы җыелма командалар: *беренче урында – Әлмәт, икенче урында – Казанның Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары, өченчедә – Кукмара, дүртенчедә – Балтач, бишенче урында – Арча, алтынчыда – Мамадыш командасы.*

Тыңлап та була, карап та

Россия Президенты Владимир Путинның Федераль Җыенга Юлламасы 21 февраль көнне 12.00 сәгатьтә башланачак. Аны «Беренче канал», «Россия 1» һәм «НТВ» каналларыннан карап була.

Президентның Федераль Җыенга Юлламасы белән «Гостиный двор» күргәзмә үзәгендә чыгыш ясавы көтелә. Дәүләт башлыгының матбугат секретаре Дмитрий Песков белдергәнчә, быел чакырылган кунаклар арасында махсус хәрби операциядә катнашучылар да булырга мөмкин. Шул ук вакытта әлеге чарага дустанә илләр журналистлары гына чакырылачак.

Песков шулай ук чакырылган, әмма авырып киткән депутатларга да киңәш биргән. «Кеше авырый икән, өйдә калуы хәерле. Чирле килеш килеп, кемгәдер иярту әйбәт түгел. Үзеңнең генә түгел, коллегаларыңның сәламәтлеген дә кайгыртырга кирәк», – дигән ул. Владимир Путинга килгәндә, вирустан ул тиешле дәрәҗәдә сакланган. «Барлык санитария-эпидемиология чаралары күрелде», – дип белдергән дәүләт башлыгының матбугат секретаре.

Ярдәм итәчәкләр

Россиядә «махсус хәрби операция балалары» дигән ташламалы категория булдырырга тәкъдим итәләр. ЛДПР депутатлары Дәүләт Думасына шуны күздә тотучы закон проекты керткән. «Российская газета» хәбәр иткәнчә, моңа балачагы (18 яшькә кадәр) махсус хәрби операция үткәрелгән төбәкләрнең берсендә узган кешеләрне кертү ниятләнә. ЛДПР лидеры Леонид Слуцкий әйтүенчә, биредә сүз Донецк, Луганск Халык Республикалары, Запорожье һәм Херсон өлкәләре генә түгел, Украина һөҗүмнәренә дучар булган чик буе өлкәләре, мәсәлән, Курск, Белгород турында да бара. Закон проектында күздә тотылганча, мондый балаларга махсус ярдәм чаралары, вакыты җиткәч, аерым законнар нигезендә туктатылачак. Бу мәсьәлә шулай ук Россия Президенты указлары яки Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә хәл ителәчәк. Төбәк хакимияте органнарына да вәкаләтләр биреләчәк.

Йә түлисе, йә эшлисе

Суд приставлары ел башыннан бирле Татарстанда бурычлылардан 58 миллион сум алимент түләткән. Бу – узган елның шушы ук чорындагыга караганда 24 миллион сумга күбрәк. Суд приставлары федераль хезмәтенең республикадагы Баш идарәсе матбугат хезмәте хәбәренә караганда, алимент түләтү мәсьәләсе буенча онлайн кабул итү уздырылган. Аңа 16 кеше язылган булган. Әмма үзләрен борчыган мәсьәлә инде хәл ителү сәбәпле, 6сы чарада катнашмаган.

Яшел Үзән районында балаларына алимент түләмәгән бер ир мәҗбүри төстә суд приставлары бүлегенә китерелгән. Бурычы 900 мең сумга якын икән. Элекке гаиләсеннән дә, приставлардан да качып йөргән. Теркәлү урыны буенча яшәмәгән. Шул сәбәпле суд приставы аны эзләтү турында карар чыгарган. Аны тапканнар. Бурычлыга карата административ хокук бозу турында беркетмә тутырганнар. Суд аны 50 сәгатькә мәҗбүри эшләргә озату турында карар чыгарган.

Сүз уңаеннан, Татарстан суд приставлары бер атна эчендә юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозучылардан (рульгә исерек хәлдә утыручылардан һ.б.) 13,3 миллион сумнан артыграк күләмдә штраф түләткән.

Сәламәтлек

Табибка эш арта

Россиядә тәмәке тарту, исерткеч эчемлекләр куллану кебек начар гадәтләр белән мавыккан үсмерләрнең исәбен ала башламакчылар. Бу җаваплы эшне табибларга йөкләргә җыеналар. Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы шундый тәкъдим белән чыккан.

Проект авторлары терапевт һәм педиатрларга участок табибы паспорты дигән яңа документ тутырта башларга тәкъдим итә. Анда шушы участокка беркетелгән, бигрәк тә психик тайпылышлары булган, физик мөмкинлекләре чикле кешеләр турында тулы мәгълүмат тупланачак. Белгечләр бирегә балаларның ничек туклануы, чакырылыш яшенә җитмәгән үсмерләрнең сәламәтлеге турында да язып барырга тиеш булачак. Моннан тыш әлеге документта мәктәптә укучы ничә баланың тәмәке тарту, исерткеч эчемлекләр куллану кебек начар гадәтләр белән мавыгуын күрсәткән саннар да урын алыр дип көтелә.

Россиянең атказанган табибы Владимир Круглый фикеренчә, әлеге проект шушы җирлектә яшәүчеләрнең сәламәтлеге турында тулы мәгълүмат тупларга ярдәм итәчәк.

– Яңа документ кеше сәламәтлеген туганнан алып картлык көненә кадәр контрольдә тотарга ярдәм итәчәк. Бүген хастаханәләрдә участокка беркетелгән кешеләрнең сәламәтлеге турында мәгълүматны бергә туплап, системага салган бер генә документ та юк. Бу яңалык – цифрлаштыру юнәлешендә дә бер адым. Бүген дәвалау оешмалары акрынлап электрон карталарга күчеп бетеп бара, – ди белгеч.

Алда телгә алынганнардан тыш, яңа документка кемгә нинди прививка ясалуы, хастаханәдә ятып чыгуы, участокта ничә кешенең яман шеш, шикәр чире, туберкулез кебек чирләр белән исәптә торуы да язылачак. Инсульт, инфаркт кичергән кешеләр дә исәптә булачак. Әлеге паспортны электрон рәвештә дә тутырып булачак. Проект авторлары бу яңалыкны дәүләт оешмаларына гына түгел, шәхси клиникаларда гамәлгә кертмәкче.

Белгечләр үзләре бу уңайдан ни уйлый? Гомуми практика табибы Наилә Гобәйдуллина бу яңалык табибларга өстәмә авырлык тудырмасмы дип шикләнә.

– Проектның асылы, аның яхшы максаттан кертелүе аңлашыла. Әмма бу безгә өстәмә авырлык тудыру булмасмы дип куркам. Соңгы елларда, укытучылар кебек үк, без – табиблар да кәгазь боткасына баттык. Ә бит без – иң беренче чиратта кешеләрне дәваларга, аларның сәламәтлекләрен кайгыртырга тиеш. Нинди генә яңалык кертсәләр дә, иң мөһиме, әнә шушы төп максатыбыздан тайпылырлык булмасын иде, – ди белгеч.

Әлеге проект уңаеннан фикер алышулар 24 февральгә кадәр дәвам итәчәк. Ул киң җәмәгатьчелектән хуплау таба калса, яңалык быелның 1 сентябреннән үк гамәлгә керәчәк. Әлеге программа 2029 елның 1 сентябренә кадәр гамәлдә булыр дип көтелә.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

Геннадий СЕМИГИН, Россия Дәүләт Думасының милләтләр эшләре комитеты рәисе:

Бу җанисәп, башланганчы ук, үз тарихында иң күп тәнкыйтьләнгән кампания булгандыр. Һәр сан белгечләрнең аңлатмасына мохтаҗ. Халык санын алу нәтиҗәләре чыкты, ә аның буенча белгечләр фикер алышуы оештырылмады. Без азаю яисә арту күрсәткечләрен генә күрдек.

(«Парламентская газета»дагы әңгәмәсеннән)

БАНКЛАРДА КҮПМЕ АКЧА БАР?

Татарстанда яшәүчеләрнең 2023 ел башына күпме акчасы банкта саклана? Россия Үзәк банкының Идел-Нократ Баш идарәсе матбугат хезмәте шул хакта хәбәр итә.

Гомуми сумма >>> 785,2 млрд

Сумнарда >>>>>>> 711,6 млрд (90,6%)

Күрәчәк булмасын

Татарстанда 843 бала онкологта учетта тора. Белгечләр әйтүенчә, соңгы елларда бу җәһәттән статистика әллә ни үзгәрми. Һәр ел саен 100–110 бала яман шеш авырулары белән исәпкә куела.

Республикада яман шештән интегүчеләр арасында балигъ булмаганнарның саны – 2% чамасы. Балаларда кан авырулары – лейкоз һәм лимфома (45%), үзәк нерв системасында (20%), сөяктә һәм йомшак тукымаларда яман шешләр, нейробластома (нерв системасындагы чир) барыннан да ешрак ачыклана.

Табиблар фикеренчә, яман чирне асылда геннардагы көйсезлекләр китереп чыгара. Авыруны башлангыч стадиядә ачыклауга (аеруча 1 яшькә кадәрге сабыйларда) диспансеризация ярдәм итә. Аның күп кенә төрләрен заманча ысуллар ярдәмендә дәваларга мөмкин. Мәсәлән, кискен лейкоздан 90% очракта котылырга мөмкин.

Ата-аналарга баланың кинәт ябыгуына, бизгәк тоту, йөткерүнең озакка сузылуы, авыр сулыш алу, төнлә тирләү, корсагы үсү, күзләре үзгәрү, башы, кул-аяклары авырту кебек билгеләргә игътибарлы булырга кирәк.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Тамак мәңге туймаса

Халыкта «туймас тамак» дигән сүз бар. Ул һич кенә дә кешенең ашап-ашап та ач калуын, туймавын аңлатмый. Ул карунлыкны белдерә. Яшерен-батырын түгел, андый сыйфат белән халыкның күп өлеше авырый. Авырмас җиреңнән авырырсың – без бит «капитализм» дигән стройда яшибез.

Капитализмның асылында милек, милекчелек, капитал ята. Синең тамагың тук, өстең бөтен, торагың яхшы, сәламәтлегең Аллага шөкерме? Булсын, шулай була күрсен, тик ул гына аз. Бүгенге яшәеш, бүгенге менталитет сиңа: «Син алар белән генә канәгать кала алмыйсың, тиеш түгелсең», – дип тукый. «Саналганнар синдә генә түгел, башкаларда бар», – ди ул. Мин-минлегең дә телгә килә: «Син үзгә, син башкалардан өстен булырга тиеш», – ди. Чыннан да, өең күрше-тирәнекеннән биегрәк, машинаң кәттәрәк икән, борынны чөебрәк йөрергә менә дигән сәбәп ярала. Кеше затының бит, бер акыл иясе әйтмешли, бай буласы килми, аның башкалардан баерак, уңышлырак буласы, ялтырыйсы килә. Бу – капитализм тудырган вектор. Хәер, капитализм гына гаеплеме икән аңа?

Матди байлыклар артыннан чабуда, фәкыйрегез «күсе узышы» дияргә яраткан ярышта калуда, ташыган малның һәрдаим аз тоелуында тагын бер сәбәп бар. Кеше – табигать баласы. Аның геномында миллион ел элек үк: «Иртәгәне белеп булмый, запас җый, «кара көн»гә әзер тор», – дип язылган нәсыйхәт-хромосома ята. Ул исән, чөнки агач башыннан төшүебезгә әле күп вакыт узмады. Игътибар иткәнегез бардыр, яңа кына тамагын туйдырган маэмайга сөяк бирсәң, ашадым, кирәкми, дип кәнфитләнеп тормый. Ала да үзе белгән урынга илтеп күмеп куя. Мантыйк гади, аңлаешлы: дөнья хәлен белеп булмый, иртәгә әллә ашаталар, әллә юк, ә мая эчне төртеп тишми. Тик менә эволюциянең башында торган homo sapiens ул табигый инстинктны бозарга («извращать» дигән русча сүз ныграк туры килә), чик-чаманы белмәскә хирысланган. Капитализм дигәндә, анысы – адәми затның шул «бозык»лыгын көчәйтүче, аңа хәер-фатиха биреп торучы строй.

Запас димәктән. Кайдадыр Һиндстанда, 50 яше дә тулмастан, эре бер эшкуар үлеп китә. Бизнесы, затлы вилласы, шәп машиналары һәм банктагы миллиард доллардан артык акчасы кала бахырның. 30ны яңа гына узган чибәр хатыны да кала. Шул хатын, озак уйлап тормастан, мәрхүмнең шоферына кияүгә чыга. Шофер дигәнебез, бәхетле никахта бер ел тирәсе яшәгәч, дусларына, беләсезме, нәрсә дигән? «Мин һәрчак хуҗага эшлим, аңа хезмәт итәм, дип уйлап йөрдем, баксаң, ул ярты гомере буе миңа эшләгән икән». Шулай, эшкуар җыйган мая, ихтимал, аның шоферына да, шоферның балаларына, оныкларына да җитәчәк. Биредә шундый мораль тумый кала алмый: беренчедән, һәртөрле «запас»та чик-чама кирәк. Икенчедән, күсе кебек, бар тапканны ояга ташыганчы, булганына шөкер итеп, аның кадерен, бәрәкәтен күреп, тормышка сөенеп яшәү күпкә кулай гына түгел, саваплы да. Тик төшендереп кара син аны халыкка.

Бер журналистның төшенә, имештер, Аллаһы Тәгалә керә. Чын журналист – төштә дә журналист, вазыйфасына тугры калып, интервью алырга керешә. Уянып киткәнче, күңелен борчыган сорауны биреп, аңа җавап алу бәхетенә ирешә. «Сине кешеләрдә булган нинди сыйфатлар ныграк борчый?» дигән сорауга җавап, имеш, шундый булган: «Алар башта ашкына-кабалана, сәламәтлекләрен югалта-югалта акча, байлык артыннан чаба, аннан соң шул акчага югалган тазалыкларын кайтару артыннан йөриләр. Алар дөньяга мәңгегә килгән кебек яшиләр дә, гел яшәмәгән төсле китеп баралар». Бу сүзләр кеше дип аталган җан иясенә, аның хәзерге аң дәрәҗәсе, тормыш рәвеше, холык-фигыленә кыскача бәяләмә түгелме? Миңа калса, нәкъ шулай.

Ялтыравыклы әйбергә кызыккан саескан кебек, без кирәгенә дә, кирәкмәсенә дә ябырылабыз шул. Кеше ала дип, модалы яңа телефон алабыз. Шуңа берәр атна кош тоткандай сөенеп йөрибез дә аннан соң онытабыз, искесеннән ничек файдалансак, шулай файдаланабыз. Ә бит кызыксынган кешегә баштан ук мәгълүм: телефондагы функцияләрнең яртысы бөтенләй диярлек кирәксез. Яңадан берничә ел үтеп, «чүлмәкчедән күрмәкче» тагын да шәбрәкне алганчы, алгач та, без ул өстәмәләрнең күбесенә игътибар да итмәячәкбез. Тик кеше бүре куа дип… Заманча автомобильләрдә дә кирәклеге шуның чаклы гына, әмма күпләрнең авыз суын китерә торган әллә күпме опция бар. Без – сабый акыллылар, шуларга ымсынабыз. Мәсәлән, автоматик парковкага. «Миндә бар ул опция», – дип шапырынырга шәп нәрсә ич. Шул дәрәҗәдә акрын эшләсә, сирәк кулланылса да, андый парковкадан соң хуҗа кеше машинасыннан чыга алмый утырса да, андый өстәмә безгә «понт», өстенлек буларак кирәк.

Унбиш бүлмәле коттедж икән, аның да гадәттә ким дигәндә ун бүлмәсе буш тора. Җиһазландырылган, җылытылган якты, матур, затлы бүлмәләр. Хуҗалар анда атнага бер дә кереп чыкмаска мөмкин. Ә өчәр яхтасы булган миллиардер? Андый яхталарның күбрәк причалда торганын, экипажның эшсезлектән газап чиккәнен әйткән дә юк, әле бит диңгезгә чыкканда, өчесенә дә берьюлы утыра алмыйсың. Ике запас яхта – аек акыл моны аңлый алмый. Россия миллиардерлары Фаберже күкәйләрен дә сатып алды. Шулар белән уйнады. Кемдер алтын йөгертелгән унитазлы виллалар булдырды. Онытмаган булсагыз, Прохоров дигән үтә бай Куршевельгә пачкалап кызлар, эскортницалар ташый иде. Ә инде иң-иң кәттәсе – югары лигада уйнаучы үз футбол командаң булу… Чиксез карунлыктан, акча күплектән гаҗизләнүчеләр чыгарган андый «мөгез»ләргә мисалларны тагын да табарга мөмкин. Алар барысы да – язма башында әйтелгән туймас тамаклык белән майга, байлыкка чыдый алмау сәбәпле ялалган «ычкыну»лар. Кирәклек, хаҗәт аркасында түгел.

Ни хикмәт, гавамның зур өлеше шундый очсызлы «кыйммәтләр»гә табына. Халык мөгез чыгаручыларга, байларга карый, шулардан үрнәк алырга, алар кебек булырга тырыша. «Кеше яшәгән, алга барган саен, ялгыш адымнарны күбрәк атламыйммы?» – дип сорыйсы килә. Телевизор, андагы кинолар безне китап укудан биздерсә, шушы гасыр җиткәч ялалган гаджетлар хат та яздырмый башлады. Машиналар шултикле күп: җәяү йөрүне оныттык, безгә гиподинамия яный. Шәһәрнең таш джунглиларында, машиналар ташкыны арасында йөреп, табигатьне, аның гүзәллеген, җанга шифасын күрми, абайламый башладык. Ыгы-зыгы, дөнья куу, «күсе чабышы» безне якадан бөтереп алган да җибәрми. Кая барып чыгачакбыз соң?

РӘИС КӨНДӘЛЕГЕ

ЭШЛЕГӘ КӨН ҖИТМИ

tatarstan.ru

Хурлык һәм оят! Татарстан Икътисад министрлыгының еллык коллегия утырышында республика башлыгы Рөстәм Миңнеханов эшләргә теләмәүчеләрне тәнкыйть утына тотты. Хәзерге бетмәс санкция шартларында җиңне тагын да ныграк сызганырга кирәклеген дә кат-кат әйттеләр. Акчаны үзебезгә табасы.

Коллегия утырышында билгеләп үтелгәнчә, дөньядагы вазгыять Татарстан икътисадына да тәэсир итмичә калмаган, билгеле. Гомумән алганда, Россиягә каршы 13 меңнән артык санкция кертелгән. Моңа да карамастан, республика сынатмаган. Узган ел йомгаклары буенча, Татарстанның тулай төбәк продукты 3,8 триллион сум тәшкил иткән. Алдагы ел белән чагыштырганда, бу 6 процентка күбрәк. Районнарга бүлеп караганда, тулай төбәк продукты күрсәткеченә иң зур өлеш кертүчеләр – гадәттәгечә, Казан (32,5 процент), Әлмәт районы (16,8 процент), Түбән Кама районы (9,8 процент) һәм Чаллы (8,5 процент) оешма-предприятиеләре. Икътисад министры Мидхәт Шаһиәхмәтов быелга бурыч та билгеләде. Агымдагы елда тулай төбәк продукты күрсәткечен 4 триллион сумга җиткермәкчеләр.

Былтыр Татарстанда импорт күләме, 29 процентка кимеп, 227,4 миллиард сум тәшкил иткән. Аерым алганда, читтән транспорт өчен запас частьлар, электр генераторлары, двигательләр азрак кайта башлаган. Импортны үзебездә җитештерелгән товарларга алмаштыру, булмаган очракта, җитештерүне җайга салуга зур әһәмият бирелә, дип тә кат-кат искәрттеләр коллегиядә.

Билгеле булганча, узган елның мартында Татарстанда санкция нәтиҗәләрен йомшарту өчен, импортны алмаштыру үзәге барлыкка килде. Ике сүз белән генә әйткәндә, бу – чикләүләргә каршы ресурслар җыелмасы. Коллегиядә катнашкан Россия икътисадый үсеш министры урынбасары Алексей Херсонцев сүзләренә караганда, анда моңа кадәр Көнбатыштан сатып алган продукциягә алмаш булырлык үзебездә һәм Россиягә дустанә мөнәсәбәттә булган илләрдә җитештерелә торган 150 меңнән артык тәкъдим бар.

Ә менә экспортны арттырганнар. Татарстаннан читкә озатылган продукция күләме 30 процентка үскән. Акча бизмәненә салсак, 15,6 миллиард сумлык товар экспортка киткән. «Чикләүләргә карамастан, әлеге күрсәткечне үстерүгә ирештек», – диде министр. Чимал һәм энергетика экспортын арттыру мәсьәләсенең көн кадагында торуын да әйтте ул.

Узган ел нәтиҗәләренә караганда, Татарстанда 234 мең 200 үзмәшгуль теркәлгән. Алар былтыр 31,4 миллиард сумлык керем алган.

– Үзмәшгульләр саны республиканың барлык районнарында да арта, – диде Мидхәт Шаһиәхмәтов. – Шул ук вакытта, алар өчен махсус ярминкәләр Татарстанның нибары 16 районында гына үткәрелә. Бу эш бөтен җирдә дә алып барылырга тиеш.

> Узган ел нәтиҗәләре буенча, республикада 15 резидент белән килешү төзегәннәр. Инвестиция күләме 2,5 миллиард сум тәшкил иткән.

Районнардагы эш сыйфатын Рөстәм Миңнеханов та тәнкыйтьләде.

– Бүген республикадагы сәнәгать паркларында 1 мең 500гә якын резидент исәпләнә. Аларда 55 меңнән артык кеше эшли. Әлеге мәйданнарны арттыру өчен бөтен шартлар да тудырылган: субсидияләр бирелә, салым түләгәндә ташламалар каралган. Тик республикадагы җиде паркта нибары берәр резидент бар. Мин бу хакта кат-кат кисәттем инде. Бүген дә әлеге районнарны кабатлыйм. Болар – Аксубай, Бөгелмә, Алабуга, Зәй, Кайбыч, Лениногорск һәм Балык Бистәсе районнары. Оят һәм хурлык! Эшләмисез бит, – диде Татарстан Рәисе.

Аның әйтүенчә, Актаныш, Буа, Яңа Чишмә һәм Мамадышта да сәнәгать паркларында эш бик сүлпән бара.

– Әлеге мәйданнар бюджет хисабына төзелде. Сез үзегез гариза җибәрдегез бит. Без сезгә акча бүлеп бирдек. Бүгенге шартларда сәнәгать парклары ким дигәндә 70 процентка тулган булырга тиеш, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул әлеге эшкә Татарстанның Инвестицион үсеш агентлыгы һәм Инвестиция-венчур фонды да җаваплы икәнен әйтте.

– Әйдәгез инде, эшләгез. Югыйсә бик матур сөйлисез, ә эшнең сыйфаты калыша, – дип мөрәҗәгать итте ул залда утыручы Талия Миңнуллина һәм Айнур Әйделдиновка Коллегиядә Түбән Кама, Чистай алгарышлы үсеш территорияләренә дә эләкте.

– Татарстанда биш алгарышлы үсеш территориясе гамәлдә. Әмма Түбән Кама былтыр бер резидент та җәлеп итмәгән, яңа эш урыннары булдыру планын үтәмәгән. Бүген коллегиягә килгәч, Түбән Кама районы башлыгын күреп, әлеге мәсьәләдә игътибарлырак булырга кирәклеген әйттем инде. Бүгенге шартларда резидентлар табу кыен икәне аңлашыла, әлбәттә. Әмма башкалар булдыра бит, – диде Рәис.

Чистай алгарышлы үсеш территориясе исә былтыр нибары ике резидентка «баеган». Бер дә матур күренеш түгел, дип фикерен җөпләде Рөстәм Миңнеханов.

Үзебезгә тырышырга туры киләчәк. Бу фикерне коллегиядә Россия Дәүләт Думасының икътисадый сәясәт буенча комитеты җитәкчесе Максим Топилин да куәтләде. Быел федераль үзәктән өстәмә ярдәм чараларына өмет итәргә кирәкмидер, дип йомшак кына, әмма аңлаешлы итеп әйтеп куйды ул. Узган елны «ил өчен дә, гомумән, тормышыбызда да иң гадәти булмаган ел» дип бәяләп, Татарстанны икътисад тармагында ирешкән уңышлары өчен мактады.

– Барысы да сәгать кебек эшләде, кулдан көйләп тә тордылар. Нишлисең, кайчак әнә шулай да эшләргә туры килә, – диде ул, алга таба да уяу булырга кирәклегенә ишарәләп.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Юлдашың яхшырак булсын

Урамда аптырап йөрмиләрме, начар йогынтыга бирешмиләрме? Юдино бистәсендәге «Юлдаш» яшьләр клубында Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты күчмә утырышында депутатлар шушы сорауларга җавап эзләде, патриотлар тәрбияләү турында сөйләште.

Депутатлар килгәндә, «Юлдаш» клубына яшьләр җыелып бетмәгән иде әле. Кемдер – укуда, кемдер эштә булгандыр, күрәсең. Клуб директоры Эльмира Сафиуллина әйтүенчә, элек бу урында икмәкханә булган. 2020 елда төзекләндереп, заманча үзәк ачканнар. Хәзер яшьләргә мөмкинлекләр эзләп, шәһәргә барырга кирәкми. Меңләгән булмаса да, йөзләгән үсмер үз урынын тапкан. 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшьләр йөри икән. Балалары белән бергәләп шөгыльләнүче әниләр дә бар. Барлыгы 12 түгәрәкнең яртысыннан артыгы бушлай.

– Клубны ачканда, яшьләрнең теләкләре исәпкә алынды. Шуңа карап, кызыклы юнәлешләр булдырдык. Берәүләр спорт белән шөгыльләнә, икенчеләр диванда утырып китап укый, дуслары белән очраша. Өйләрендә компьютер булмаганнар өчен дә мөмкинлекләр тудырылган. Бигрәк тә кыяга менү, җиңел атлетика, бокс юнәлешләре популяр. Телисең икән, театр студияләре, бию түгәрәкләре бар, – ди Эльмира Сафиуллина. – «Алдынгылар хәрәкәте» юнәлеше буенча балалар туплый башладык.

Балаларның урам тәрбиясенә бирешкәннәре дә бар. Андыйлар клуб турында дусларыннан ишеткән. «Безгә килгәч, үзгәрәләр. Тренерлардан үрнәк алалар. Патриотик тәрбиягә багышланган чараларның күбесендә егетләр катнаша», – диде клуб җитәкчесе.

Казандагы «Патриот» берләшмәсе җитәкчесе (монда 60тан артык оешма керә) Екатерина Согрина үсмерләр клубларының өй яныннан ерак китмичә генә шөгыльләнү, тәртип бозучыларны туры юлга бастыру өчен кирәклегенә басым ясады.

– Кайбер клублар махсус спорт, техник, көрәш юнәлешләрендә. Кайберләрендә кызлар тырнак, прическа, макияж ясарга өйрәнә. Әмма яшьләр үзәкләренең күбесе төрле төрдәге түгәрәкләрне үз эченә алган, – диде ул.

Аның әйтүенчә, кайчандыр полициядә исәптә торган егетләр хәзерге яшьләр көчле рухлы булсын, хаталанырга урын калмасын өчен, бар көчен куя. Арада бокска өйрәтүчеләре дә бар. Җәмәгать тәрбиячеләре дә үз өлешен кертә. Урамнарга чыгып, үсмерләрне клубларга алып килеп, алар белән бергәләп спорт белән шөгыльләнә икән.

– Быел беренче тапкыр «Ышаныч» үзәге белән берлектә өч клуб ачылачак. Анда психологлар да эшләячәк. Бер өлешендә спорт белән дә шөгыльләнергә мөмкин. Элеккеге клублар системасына кайтабыз. Анда социаль педагоглар да, психологлар да бар иде, – диде Екатерина Согрина.

Клубтагы мөмкинлекләр белән танышканда, Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана Захарова тренерлар мәсьәләсе турында кызыксынды. «Теләүчеләр бар, әмма ставкалар җитми», – дип җавап бирделәр клуб белгечләре.

Комитет утырышы башлангач, Светлана Захарова бүген яшьләргә патриотик тәрбия бирү мәсьәләсенең мөһимлегенә тукталды.

– Без хакимиятнең барлык тармаклары белән бергә эшләргә, мөмкин кадәр күбрәк җәмәгать оешмаларын җәлеп итәргә тиеш. Безнең төп бурыч – балаларны, яшьләрне урамнан һәм чит идеологиянең тискәре йогынтысыннан аеру, – диде Светлана Захарова.

Татарстан Рәисе ярдәмчесе, «Алдынгылар хәрәкәте»нең республика бүлеге җитәкчесе Тимур Сөләйманов белдергәнчә, хәзерге балалар ким дигәндә көнгә биш сәгать вакытын социаль челтәрләрдә уздыра. Интернет проблемага әйләнмәсен өчен дөрес юлларны табарга кирәк. «Алдынгылар хәрәкәте» актив кына түгел, игътибар җитмәгән балаларны да колачларга тиеш. Бер үсмер дә читтә калмасын», – диде ул.

Депутатлар патриотик тәрбия бирүне мәктәп укучылары гына түгел, студентлар, эшче яшьләр, әти-әниләр арасында да активлаштырырга кирәклеген әйтте.

Сәрия МИФТАХОВА

1 марттан хайван тиресләрен, чүпләрен, тизәкләрен, мал-туар асларын эшкәртүгә бәйле яңа закон гамәлгә керәчәк. Нәрсә үзгәрәчәк? Без шул хакта белештек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ТИРЕС КЕНӘ ТҮГЕЛ

Россельхознадзорның Татарстан идарәсе мәгълүматлары буенча, халыктан фермалар янындагы тирес, сасы исләр, пычрак суларга кагылышлы зарлар әледән-әле килеп тора. Алар аеруча февраль – март айларында активлаша икән. Әйтик, узган ел терлек комплекслары һәм кош фабрикаларыннан чыккан һәм кырларга тирес түккәндә таралган сасы ис буенча 385 шикаять алынган. Шуңа күрә әлеге мәсьәләгә ныклап тотынырга булганнар. 1 марттан авыл хуҗалыгы оешмаларында кулланыла торган калдыклар терлекчелекнең өстәмә продукты булып саналачак һәм туфракка бары тик эшкәртеп кенә кертергә рөхсәт ителәчәк.

– Яңа закон буенча, өстәмә продуктлар калдык булып исәпләнми. Терлек тоткан хуҗалыклар калдыкларны җитештерүнең өстәмә продукты буларак куллануны үзләре хәл итәргә һәм бу хакта Россельхознадзорга хәбәр итәргә тиешләр. Ягъни әгәр хуҗалык тиресне өстәмә продукт дип билгели икән, аларны махсус урында кимендә биш ай череткәннән соң, туфракка кертергә тиеш булачак. Законның төп максаты – барлык шартлар үтәлеп ясалган органик ашламаны туфракка кертеп, җирнең уңдырышлылыгын арттыру. Билгеле булганча, туфракка кертелә торган черемә барлык шартлары туры килгән очракта гына файдалы булачак. Органик ашлама бакчачылыкта бик актив файдаланыла, – дип аңлатты Россельхознадзорның Татарстан идарәсе дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге башлыгы Идрис Гатин.

Аңлатып узабыз: әлеге яңалыклар шәхси хуҗалыкларга кагылмый. Ул бары тик терлекчелек, кошчылык, дуңгызчылык белән шөгыльләнүче фермер һәм эре агрохолдинглар, эшмәкәрләр эшчәнлегенә генә карый.

Терлекчелекнең өстәмә продуктларын дөрес файдаланмаган очракта, штраф белән дә яныйлар. Күләме дә шактый: 30 мең сумнан алып 450 мең сумга кадәр.

Әлегә республика тирес, тизәк кебек терлек калдыкларын оешмаларда эшкәртү белән мактана алмый. Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының матбугат үзәге җавабыннан аңлашылганча, әлегә Татарстанда калдыкларны заманча технологияләр кулланып утильләштерү буенча проектлар бармак бөгеп санарлык кына.

– Аларның берсе Азнакайның «Союз-Агро» оешмасында эшли. Күптән түгел танылган хоккейчы Данис Зарипов та кош тизәген ашлама буларак эшкәртү буенча комплекс төзү планнары белән уртаклашкан иде. Дөрес, әлегә проект финансланмаган, – диделәр.

Дәүләт Советының экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе Азат Хамаев әйтүенчә, республикада 2000 нче елларда кош-корт тизәген эшкәртү буенча фикер алышулар булган инде, ләкин, күрәсең, эшләр лаборатория тикшеренүләреннән ары узмаган. Азат Хамаев фикеренчә, монда беренче чиратта агропредприятие хуҗаларының кызыксынуы булырга тиеш.

Әлеге үзгәрешләрне эре хуҗалыклар, фермерлар ничек кабул иткән? Яңалык аларны көендергәнме, әллә сөендергәнме? Азнакай районы фермеры Илмир Гарәфиев әйтүенчә, фермерлар тирес мәсьәләсендәге үзгәрешләрне узган көздә үк сизгән.

– Махсус урыннарга өелгәнме-юкмы икәнлеген килеп, тикшереп киттеләр, аңлату эшләре алып бардылар. Без бит инде тиресне өеп, черетеп кенә басуга кертәбез. Махсус эшкәртү дигән әйбер юк. Череткәннән соң, ашлама буларак кулланыла, – диде ул.

Саба районының Мәртен авылы агрофирмасында Лимузин токымлы сыерлар үрчетәләр. Аның җитәкчесе Әскәр Фатыйхов әйтүенчә, маллар ишле булгач, калдыклары да күп.

– Тирес – дөньядагы иң яхшы ашлама. Без хайван тизәкләрен, тиресне бары тик басуларга гына кертәбез. Моңа кадәр аларны турыдан-туры түгә идек, быелдан бары тик черетеп кенә кертәсе булачак. Моның өчен фермадан ерак түгел генә махсус мәйданчыкларыбыз бар. Шунда техника белән ташып өябез дә, черемә хәленә килгәч, басуларга кертәбез, – диде ул.

Әскәр Фатыйхов әйтүенчә, яңалык аларның эшчәнлегенә артык мәшәкать тудырмаган.

– Бу эшне электән үк башлыйсы иде. Янган тиресне басуларга кертү, тарату да уңайлырак. Шуңа күрә гамәлгә керәчәк законның авырлыгын, кыенлыгын тоймыйбыз, – диде ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БЕЛӘЛӘР ДӘ КЕБЕК, ӘММА БЕЛМИЛӘР

Ил уллары

15 февраль – татар халкының каһарман язучысы, Ленин орденына лаек булган бердәнбер шагыйребез, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең һәм татар халкын берләштерүгә бөтен гомерен багышлаган, татар моңын дөньяга танытучы легендар җырчыбыз Ильһам Шакировның туган көннәре.

Шушы уңайдан Бөтендөнья татар конгрессы һәм милләтебезнең затлы, зыялы шәхесләре, бөтен дөньяга сибелеп яшәүче халкыбызга мөрәҗәгать итеп, Муса Җәлил һәм Илһам Шакировка багышланган мәдәният атналыгы марафонын игълан итте.

Бу акцияне бер ел элек «Җиһангирлар» инициатив төркеме җитәкчесе Хәлил Гайнетдинов белән Татарстанның халык артисты Гөлзадә Сафиуллина оештырган иде. Татарстан Мәдәният министрлыгы да, Бөтендөнья татар конгрессы да яңалыкны бик тиз күтәреп алды. Оештыру эшләрен Татар конгрессы үз кулына алды.

Күпләрне гаҗәпкә калдырып, быелгы чара Салих Сәйдәшевнең «Кызыл Армия маршы»ннан башланды. Моның сере дә, проект җитәкчесе Гөлзадә ханымның бер тәкъдиме дә бар икән.

– Безнең ил улы дип аталырга лаек шәхесләребез бик күп. Ни кызганыч, күпләре онытылып бара. Әйдәгез, ел саен без бу исемлеккә берәр кешене өсти барыйк. Мин Салих Сәйдәшевны да тәкъдим итәр идем. Сәбәбе дә бар. Күренекле композиторыбызның музее ябылганга алты ел була инде. Яңасын дүрт ел эчендә төзегәннәр иде. Ниндидер сәбәпләр белән ике ел инде ачылмый тора. Бу эштә җәмәгатьчелекнең дә ярдәме кирәк дип уйлыйм, – диде ул. Акциянең исеме турында да сүз булды. Тора-бара «кызлары» сүзен дә өстәргә кирәк булмасмы икән әле? Безнең хатын-кызларыбыз арасында да күренекле шәхесләребез байтак бит, дигән фикерләр ишетелде.

Бөтендөнья татар конгрессы җитәкчесе Данис Шакиров башка чараларны да искә алды.

– Инде бишенче мәртәбә Халыкара Җәлил укуларын үткәрәбез, – диде ул. – Быел Россиянең төрле төбәкләреннән, чит илләрдән 816 кеше катнашты. 38 төбәктән 115ен сайлап алдык. 17 февраль көнне нәтиҗәләр ясарга уйлап торабыз. «Илһам чишмәләре» дип аталган бәйгедә җиңүчеләргә Илһам Шакиров исемендәге премияләр тапшырабыз. Бу чараларга яшьләр бик тартыла.

Бу җәһәттән сүзгә тарих фәннәре докторы Фаяз абый Хуҗин да кушылды.

– Яшьләр дигәндә, уйландыра торган нәрсәләр күп инде, – диде ул. – Менә студентлар Муса Җәлилне беләләр дә кебек, әмма тәфсилләбрәк сорый башласаң, берни белмиләр. Димәк, мәктәпләрдә нииндидер бушлык хөкем сөрә. Шулай да Илһам Шакиров моңы халык күңеленнән мәңге китмәс дип уйлыйм. Татарны җыр, моң саклый дип юкка гына әйтмиләрдер ул. Ә күз уңыннан югала баручылар, чыннан да, күп. Мәсәлән, СССРның халык артисты Азат Аббасов. Онытыла бара кебек. Бу хәлне булдырмас өчен бик киң, бай, күренекле шәхесләребез турында сөйләрлек театр һәм музыка сәнгате музее кирәклеге көн кебек ачык. Бу хакта узган ел да сүз кузгаткан идек, тукталып калмыйсы иде. Бәлки, яңасы төзелгәч, Камал театры бинасы тәгаенләнер. Алдан ук чарасын күреп, бу проблеманы якын арада хәл итәргә кирәк.

Салих Сәйдәшев турында сүз чыккач, музыка белгече Эльмира Ханиева композитор тормышындагы «ак тап»ларны да барлап китте.

– Музейда эшләгәндә, Салих Сәйдәшев турындагы һәр мәгълүматны үз кулым аша үткәрдем. Мәсәлән, без аның Үзбәкстанда эшләгән чоры турында бернәрсә дә белмибез икән. Ул анда 1920–1928 елларда рәсми төстә татар театрының баш режиссеры булып эшләгән. Композитор, үзе теләп, Гражданнар сугышына китә, Төркестанда хезмәт итә. Шунда төрле музыка коралларында уйный. Кәрим Тинчурин чакыруы буенча 1922 елда Казанга кайта, әмма җәйләрен артистларны «ирек»кә җибәрү сәбәпле, алар төрле җирләргә таралыша. Салих Сәйдәшев та дуслары янына Үзбәкстанга китә. Кәттә-Курган шәһәрендә театр оештыра. Бик дәрәҗәле театр була ул.

Аның сүзенә кушылып, тәнкыйтьче, әдәбият галиме Миләүшә Хәбетдинова, бу фактларның һәрберсен интернет челтәренә кертә барырга кирәк, диде. Безгә сәнгать комиссиясе кирәк дип утыручыларга да аның җавабы бер булды.

– Бездә комиссияләр күп ул. Ниндиләре генә юк. Аларның эшләгәнен көтеп тын гына утырасы түгел. Фикер туплап, торып басарга да, һәрберебезгә ниндидер максат белән бер адым алга атларга кирәк. Аннан икенчесен. Шул вакытта без алга таба китә алырбыз. Эшләнәсе эшләрнең бик гадиләре, зур чыгымнар сорамый торганнары да бар. Безнең урамнарда радиолар Илһам Шакиров җырларын, Салих Сәйдәшев көйләрен яңгыратып торырга тиеш. Тавыш эффекты дигән әйбер зур роль уйный. Гел колакка ишетелеп торгач, кеше үзеннән-үзе тартыла башлый.

«Ил уллары» акциясен үткәрү өчен һәркем үзенчә яңалык эзли. Кооперация институтының мәдәният үзәге җитәкчесе Флюра Абдуллина да 15 февраль көнен төрле форматта үткәрергә тырыша.



Быел ул Муса Җәлил белән Илһам абыйның яраткан ризыклары турында белешкән. Чулпан ханым аңа: «Әтием хатларында әнигә, синең пәрәмәчләреңне, өчпочмакларыңны, токмачлы ашыңны сагынам, дип яза торган иде», – дигән. Ә Илһам абый турында туган авылына шалтыратып ачыклаган: җырчының иң яраткан ризыгы кабак бәлеше белән токмачлы аш булган икән. Шул ризыкларны пешереп, шигырьләр сөйләп, җырлар җырлап, студентлар белән бик матур бәйрәм ясаганнар.

– Институт янында Муса Җәлил белән көрәштәшләре куелган «Батырлык» аллеясы ясадык. Шунда чаралар үткәргәндә, сыгылып басып торган егетләр янына киләм дә, батырлар кебек горур, төз басып торыгыз, дим. Шундук сыннарын турайталар. Бик яхшы тәэсир итә, – ди Флюра ханым.

Яңалыклар дигәннән, Рөстәм Сәрвәровның тәкъдиме бик саллы булды. Ул: «Татар конгрессы аша дөньяга сибелгән татарлар арасында Муса Җәлил сүзләренә язылган җырларга конкурс игълан итәргә кирәк. Аның бик аз шигырьләренә генә көйләр язылган бит. Җырлар аша исемен күбрәк, еракларак тарата алыр идек», – диде.

Атналык дәвам итә. Балалар бакчаларында, мәктәпләрдә Муса Җәлил шигырьләре яңгырый. Иртә белән укучыларны Илһам абыйлары җырлап каршы ала. Радио-телевидениеләр, матбугат чаралары бу вакыйгага зур игътибар биреп, яңадан-яңа мәгълүматлар эзли. Мәдәният йортларында Муса Җәлил шигырьләреннән, Илһам Шакиров җырларыннан концертлар әзерләнә. Социаль челтәрләр бу көннәрдә бигрәк тә актив. Димәк, 15 февраль – бөтен дөньядагы татарларны берләштерә торган көн ул.

Катнашучыларның Муса Җәлил шигырьләрен укыган яки яттан сөйләгән, Илһам Шакиров репертуарындагы җырларны башкарган, мәшһүр талантларыбыз турында истәлекләр белән уртаклашкан видеоязмаларын #татарууллары2023 дигән хештег куеп, үзләренең «ВКонтакте» социаль челтәрендәге шәхси битләрендә урнаштырырга чакырабыз. Өстәмә сораулар булган очракта gulzadasafiullina1946@gmail.com электрон почтасына мөрәҗәгать итә аласыз.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Соклану

Бер йодрыкка тупланып

Туып-үскән җирен онытмаганнар сокландыра. Эштән бушаган чакларында туган якка тартыла алар. Күпләргә үрнәк итеп тә куялар үзләрен. Ни дисәң дә, авыл белән шәһәр арасын якынайтып яшәүләренә 30 ел инде.

Җәмгыятьне элек-электән күренекле шәхесләр җитәкләгән. Аның беренче җитәкчесе булып, тумышы белән Коштавылдан булган, мех эшләнмәләре фабрикасы директоры Шәүкәт Кәлимуллин сайлана. Аннан соң әлеге вазыйфа Татарстанның физик культура һәм спорт дәүләт комитеты җитәкчесе урынбасары Мансур Мифтаховка йөкләнә. 1997–2010 елларда Кызыл Тау авылында туып-үскән, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Хәлим Гайнуллин җитәкчелек итә. 2011–2020 елларда якташлык җәмгыятенең президенты Азат Хәнифәтуллин була. Хәзер исә бу эшне Дәүләт Думасы депутаты Марат Нуриев алып бара. Җәмгыятьнең вице-президенты Наил Галиуллин исә, остазлар башлаган эшне матур дәвам итәбез, ди.

– Нәрсәгә генә тотынсак та, бу бит – безнекеләр, дип әйтерлек булсын дип эшлибез, – ди ул. – Апас җирлегендә туып-үскән якташларны барлауны дәвам итәбез. Максатыбыз – бер йодрык булып туплану. Бәлки, алар арасында олы яшьтәге кешеләр, туган нигезе беткәннәр бардыр. Әнә шуларны табып, ялгыз түгеллекләрен исләренә төшерәбез. Якташлык эшендә яшьләр читтә кала иде. Узган ел исә Апастан чыккан яшьләрне барлый башладык. Алар белән очрашулар уздырдык. Социаль челтәрләрдә дә актив эшлибез.

Якташлык, яшьләр белән элемтәне ныгыту максатыннан, төрле чаралар уздыра. Күптән түгел иншалар бәйгесе үткән. Район укучылары бәйгедә теләп катнашып һәм күренекле якташларыбызның тормыш юлын, иҗатын барлаган.

– Апастан гына түгел, Чаллы һәм Әлмәт якларыннан да иҗат эшләре килде. Әлеге эшебез туган төбәгебез белән бәйләүче бер күпер булып тора, – ди Наил Галиуллин.

Апаслыларның иң зур өстенлеге – Казанда җыелыр урыннары бар. Шуның белән бәхетле дә алар. Менә шунда төрле идеяләр туа, бергәләп яңа эшләргә планнар коралар. Хәер, аларның эшсез торганнары да юк. Монда мисал итеп Коштавылны күрсәтергә була. Якташлар авыл яшәсен өчен кулдан килгәнне эшли. Төрле бәйрәмнәр уздыралар, бигрәк тә балаларның күңелен күрер өчен берни кызганмыйлар. Нәкъ менә авылда яшәүче сабыйлар өчен дин сабаклары да укытыла. Ул тулысынча иганәчеләр ярдәме белән башкарыла. Укырга килүчеләрне тәмле ризыклар белән дә сыйлыйлар. Бу эшләрнең күбесен шушы авыл егетләре – Наил Галиуллин белән Россиянең атказанган табибы Рәшит Байбиков оештыра.

– Салаларның сүрелүе, анда балалар санының кимүе йөрәкне әрнетә. Авылны яшәтәсе килә. Шуңа сабыйларның күңелен күрергә тырышабыз. Бәлки әле, үсеп җитеп, туган якларында төпләнеп калырлар. Ел башында сабыйларны җыеп, курчак театры да күрсәттек. Безнең авылга җырчылар да еш кайта. Төрле бәйрәмнәр дә уза. Моның өчен авылыбызның мәдәният йорты җитәкчесе Тәскирә Хафизовага рәхмәт, – ди Наил Галиуллин. – Кайда гына яшәсәң дә, туган якны онытмаска кирәк. Хикмәт кесә калынлыгында гына түгел, күңелең изге булсын! Зиратны тәртиптә тоту да кирәк. Мәчеткә йөрүчеләр дә булсын, дибез. Күңелле чаралар да уздырасы килә. Якташлар читтәгеләрнең җылысын тоярга тиеш!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Келәмнең кызган чагы

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Келәм күрсәтер

Инде әйтелгәнчә, быелгы турнир 350ләп көрәшчене җыйды. Елдагыча, Татарстан гына түгел, чит төбәкләрдән дә килүчеләр бар. Иң осталары шимбә көнне ачыкланачак. Көрәшчеләрнең кайсы янына килеп, хәлен сорасак та, «Җиңсәм, бик яхшы булачак», – дигән кыска җавап алдык. Җаваплы бәйге булгач, бар игътибарны көндәшләрен җиңүгә юнәлткән алар. Яннарында үзләре дә келәмгә чыгарга әзер торучы тренерлары белән дә сөйләштек.

– Яхшылап әзерләндек әзерләнүен, ләкин күп нәрсә җирәбәдән тора бит. Көчле көндәшләр туры килде. Шулай да, көчлене җиңмичә, көчле булып булмый. Калганын келәм күрсәтер, – диде үзе дә әлеге турнирны дүрт тапкыр откан, хәзерге вакытта Балтач районы командасының тренеры Ринат Хәйретдинов.

Муса Җәлил турниры – көрәш сөючеләрнең дә яраткан бәйгесе. Тумышы белән Йошкар-Оладан булган, хәзерге вакытта Казанда яшәүче Габдерәүф абый шулай ди.

– Казандагы гына түгел, Зәйдә узган турнирны да карарга насыйп булды. Безнең көрәш матур инде ул. Ярышларны калдырмаска тырышам. Бүген бераз соңрак – көрәшнең кызган чагына туры китереп килдем. Ә финал ярышларын башыннан ахырына кадәр карарга ниятлим. Якташым Муса Галләмов өчен җан атам. Ярышлар турында да ул хәбәр итә миңа, – дип сөйләде ул безгә.

Көрәшчеләргә тарихка кереп калачак турнирда җанатарларның өметләрен аклап, ә иң мөһиме, имгәнмичә, матур көрәш күрсәтергә язсын!

КОТЛЫЙБЫЗ!

«Берлек» авыл хуҗалыгы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры (Татарстан Республикасының Баулы районы) **Абдуллин** Фатыйх Сәет улына, «АЛГА» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш бухгалтеры (Татарстан Республикасының Актаныш районы) **Закирова** Рәмүзә Наил кызына, «Мортазин Раеф Тимерҗан улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы (Татарстан Республикасының Мөслим районы) **Мортазин** Раеф Тимерҗан улына, «Балтач районы дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең Карадуган ветеринария участогы мөдире – ветеринария табибы **Хәсәнов** Равил Исмәгыйль улына, Тимирязев исемендәге җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автотранспорт цехы башлыгы (Татарстан Республикасының Балтач районы) **Хафизов** Рифкат Харис улына, Татарстан Республикасының «Республика ветеринария лабораториясе» дәүләт бюджет учреждениесе директорының эпизоотиягә каршы эш буенча урынбасары – ветеринария табибы **Һашимов** Рөстәм Илдар улына, «КАМА» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең автомобиль йөртүчесе (Татарстан Республикасының Тукай районы) **Шакиров** Рафаэль Рәхимҗан улына, «Татарстанның агробизнес кадрларын яңадан әзерләү институты» федераль дәүләт бюджет өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениесенең агросәнәгать комплексы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү технологияләре кафедрасы профессоры **Шилов** Валентин Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык беренче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык беренче утырышын 2023 елның 22 февралендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 16 феврале
№ 1828-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык беренче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык беренче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкару турында.
2. 2022 елда полиция эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры хисабы.
3. 2022 елда Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеге турында доклад.
4. «Өстенлек-2030» стратегик академик лидерлык программасы кысаларында 2021 – 2030 елларга «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесен үстерү программасын гамәлгә ашыру турында һәм 2022 елда Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеш хакында хисап.
5. «Федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредитлары бирү турындагы килешүләргә өстәмә килешүләр хакында» 382-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 393-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
7. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 385-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 388-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
9. «Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында булган мәҗбүри таләпләрне билгеләү һәм аларны куллануны бәяләү һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына экспертиза ясау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 391-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 389-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
11. «Татарстан Республикасында ветеринария эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 392-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 386-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 42 һәм 43 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 387-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 384-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында.
15. Татарстан Республикасы Хисап палатасына йөкләмә турында.
16. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Социаль сәясәт комитетының 2019 елның сентябреннән 2023 елның февраленә кадәрге эш чоры өчен хисабы.
17. Балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып бару чоры балалар учреждениеләрендә педагогик эшчәнлек алып баручы затларга картлык буенча хезмәт пенсиясен вакытыннан алда билгеләү хокукы бирүче эш стажына кертелә торган вазыйфалар һәм учреждениеләр исемлегенә үзгәрешләр кертү турында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
18. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 289051-8 номерлы федераль закон проекты хакында (керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне тикшерүне уздыру тәртибен камилләштерү һәм белешмәләрнең тулылыгы өлешендә).
19. «Дарулар әйләнеше турында» Федераль законның 53 һәм 67 статьяларына һәм «Эшчәнлекнең аерым төрләренә лицензия бирү турында» Федераль законның 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 284099-8 номерлы федераль закон проекты турында (халыкара патентлаштырылмаган «Этанол» исемле дару препаратларын җитештерү күләмен һәм аларның әйләнешен исәпкә алуны камилләштерү өлешендә).
20. «Россия Федерациясе Торак кодексының 161^{1} статьясына үзгәрешләр кертү турында» 272604-8 номерлы федераль закон проекты хакында (күпфатирлы йорт советы рәисенең күпфатирлы йорттагы милекчеләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итү процедурасын гадиләштерү өлешендә).
21. «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» Федераль законның 3 статьясына һәм «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның 11 һәм 16.5 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 263340-8 номерлы федераль закон проекты турында (торак-төзелеш кооперативына әгъза итеп алынырга мөмкин булган гражданнар категориясе исемлеген киңәйтү өлешендә).
22. «Россия Федерациясе Җир кодексының 39^{11} статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Чиләбе өлкәсе Закон чыгару Собраниесе закон чыгару инициативасы турында.
23. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елын үткәрү йомгаклары турында».

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе
Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2023 елның 16 феврале
№ 1829-VI ДС

Авыл язмалары

Син яз әле, энем...

Илдар Мөхәммәтҗанов

И энем, кайчагында мин әллә нәрсәләр уйлап бетерәм. Дөньяның иң ачыган ахмагына да килми торган сантый уйлар туа кайвакытта. Аптыраганнан инде барысы да. Аптыраштa калган кеше ул ахмактан артык ерак булмый бит инде. Хәзер менә шуларның берсен сиңа да сөйләп күрсәтәм әле.

Менә без гел, акча житми, акча юк, дип зарланабыз. Бар ул, энем. Акча булмаса, иң беренче булып акча ясаучылар акча үләр иде. Ә алар үлми. Эшсезләр арасында да я җыен галим-голәмә, я мөгаллим-тәрбияче. Ә акча ясаучыларның берсе дә эш эзләми. Берсе дә базарга барып, ит чабып та йөрми, каравылга да керми, кибеттә дә сатмый. Димәк, эшләре бар. Димәк, акча ясап торалар. «Денга есть» дигән сүз бит инде шулай булгач. Ә без юк дип зарланабыз. Менә минем бишмәтнең дә юк ягтагы кесәсендә бер тиен юк. Пенсиямне шунда салып барам. Ә менә сул якатагысында – сулдан кергән хәзинә, анысы бер генә дә буш тормый. Хәзер менә сул кесәмнән алам да уңына салам – ике кесәмдә дә бар. «Акча юк» дигән сүз ул аның юклыгын түгел, ә ятлар кесәсендә булуын аңлата. Кара әле, энем, акча дигәч, яңакларың алсуланып китте... Ашыгдан да туктадың... Тик фикер сөрешен син чамаласын өчен генә әйтелгән сүз иде бу. Тере ахмаклыкның арифметик ягы гына. Ә асылы менә болайрак аның, энем.

Шәһәр җирендә бомжлар күп, дип яза идегез бит элгәрәк. Хәзер бик күренми. Тик алар бетмәгәндер инде, язмаска гына куша торганнардыр. Шәһесне кимсетү кебек яңгырый дип әйтәләр бит. Безнең дәвердә аларны «бич» дип йөртәләр иде. Ул инглиз теленнән кергән сүз икән, ярга чыгарып ташланган дигәнне аңлата. Тормыш дулкыннары ярга чыгарып аткан кешеләрне шулай йөрткәннәр элек. Хәзер «бомж» диләр инде. Милиция теркәгәнчә кыланалар. Яшәү урыны билгеле булмаган кеше. Татарча бик мәсхәрәле яңгырамый. Безнең тел ул шундый ягымлы инде. Күңел дә иркен.

Шул бомжлар арасында бик гыйлемле, якты күңелле кешеләр дә була икән дип ишеткәнем бар. Аларның кайберләре әле карт-корыны, әле бала-чаганы авырлыклардан, хәтта һәлакәттән коткарып, әллә нинди батырлыклар да эшләп ташлый икән. Яхшы кәчтүмнәре булмагач, түшләренә мидал тагучылар гына юк. Ништелисең инде... Беркемне дә гаепли торган түгел... Заманны әллә нишләттек бит хәзер, тормыш дулкыннары нәкъ менә шундыйларны сындырырга тырыша, шундыйларны ярга чыгарып бәрә.

Аннан соң, бомж исемләренә кермичә генә торыр урын тапмый йөрүчеләр дә байтак бит ул шәһәрдә. Кеше өстендә яшәүчеләр купме. Эш урыннары булып, салымнарын түләп баргач, аларын адәм чутына кертәләр инде. Кредит белән ипотека алыр өчен дә шулар кирәк бит. Әле менә тиге ситан Гатаулла малае кайткан. Фатир снимайт итәбез, кредитка яшибез, ди. Хезмәт хакы фатирга түләргә дә, банкны баетырга да җитә, дип шөкер итә. Кайт авылга, миняйтәм, йорт-куралны карарсың, мал-туар асрарсың, туган җиреңә аяк тереп тормыш корырсың, авылын гел балда-майда булыр. Юк, итә китереп булмый. Чат ябешкән шул шәһәренә. Соң өч тиенлек кадерең дә булмаган җиргә биш тиен түләп ябешеп аталармыни! Шуны күргәч туды инде әлеге уй...

Авыл бетә, диеп борчылам инде. Барыда да оҗмах эзләп китә: яшьләр – шәһәргә, карт-коры – тегедөньяга. Олы бер урамда дүрт-биш кенә кеше яшибез. Буш йортларның чиге-чамасы юк. Шуннан уйладым-уйладым да сиңа әйтергә булдым. Тегe бомжлар арасында яшь, акыллы, миһербанлы татарлар юк микән? Булса, авылга кайтсыннар әле. Мунча кереп, арурак кием киеп алсалар, шәһәрдә ничек йөргәннәрен беркем дә белми бит инде аларның. Белсә дә ятка сөйләми. Яшәп китәрләр иде матур гына итеп. Барысы да тылсымлы бит монда: җәй көне җиләкжимеш, яшелчә сихәт бирә, кышларын – кар көрәге. Бомжлар булмаса, фатир снимайт итүчеләр кайтсын. Алар арасында акыллылар булмый калмас әле. Кредит түләү акыл кертә бит ул. Акча тапкан кебек авырдыр инде андыйларны эзләү. Тик күңелең җиңел, бер кесәдән икенче кесәгә салган кебек кенә...

Уэбсезнең татарлар кайтсын түлке. Башка халык ул хуҗа булырга ярата, кучеп килгән җирем диеп тормый. Әнә тере вакытта ике хатын кайткан иде, авылның бөтен ирләренә хуҗа булдылар...

Уэем язар идем, күзләр курми. Син яз әле, энем, шушыларны...

Марат КӘБИРОВ

КФУ СТУДЕНТЫ РИЗӘЛӘ ГЫЙЛӘҖЕВА:

«ТЕЛ УКЫТЫП БАЕП БУЛА»

Үрнәк

КФУның филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының 4 нче курсында белем алучы Ризәлә Гыйләҗева «Асылташ» мәктәбендә татар теле дәресләре укыта. Телне өйрәтү өчен методик әсбап та булдырган. Дәресендә бер рус сүзе дә әйтми. Ул – КФУның гуманитар һәм икътисадый фәннәр өлкәсендә «Ел интеллекты» бәйгесе лауреаты.

– Минем өчен иң мөһиме – мохит тудыру. Балаларга алдан ук: «Мин русча белмим», – дип әйтеп куйдым. Шуңа күрә дәрестә татарча сөйләшергә тырышалар. Белмәгән сүзләрен тәрҗемә итмим. Әгәр ятрак сүз икән, мәгънәсен аңлатам. Алар шуннан үзләре уйлап таба. Таба алмыйлар икән, рәсем күрсәтәм. Бер кайчан да, белмибез, димиләр. Аларны уен аша сөйләмгә өйрәтәм. Мохитсез тел яши алмый, шуңа күрә уз туган телеңдә бары аралашырга гына кирәк: өйдә, балалар бакчасында, мәктәптә, дус, туганнар җыелган җирдә, – ди башлангыч сыйныф укытучысы Ризәлә Гыйләҗева.

Яшел Үзән районының Күгәй авылы кызы Ризәлә рус, инглиз телләрендә камил сөйләшә. Дәрес, баштарак инглиз теле белән мавыгып китеп, киләчәктә шул телне укытырмын дип уйлаган. Әмма «Сәләт» хәрәкәтенең Казандагы 51 нче мәктәп базасында өч ел элек ачылган «Асылташ» мәктәбендә эшли башлагач, фикере үзгәргән. Милли мохит, шәһәр әтиәниләренең балаларына татар телен өйрәтү теләге, сабыйларның күзләрендәге очкын сәбәпче булган моңа. Асылташлылар беренче көннән үк аның йөрәген яулаган. Хәзер ул: «Юк, мин укучыларга ике телне дә өйрәтәчәкмен», – ди.

Ризәлә үзе укыткан мәктәпне башка бер галәм дип атый. Монда балалар кичке сәгать алтыга кадәр шөгыльләнә. Сыйныфларны сафлар дип йөртәләр. Дәресләрдә актив, яхшы укышларга ирешкән укучының көндәлегенә – «асылташ», ә ей эшен эшләмәгән, дәрескә соңга калганнарга «тәртип» тамгасы куела. Менә шундый кызыклы система белән эш итәләр.



Ризәлә әйтүенчә, мәктәптә авыр холыклы балалар юк диярлек. «Сәләт» – тәрбия биру мохите, ләкин тәрбиясезне төзәтү мохите түгел. «Без яхшылыкка тартылып үсәбез, начарлыктан этәрелеп түгел. Монда асыл әти-әниләрнең тәртипле, әхлаклы балалары гына укый», – ди студент укытучы.

– Ничек уйлыйсың, татар телен өйрәтеп баеп буламы? – дип тә сорадык аннан.

– Әлбәттә, була. Мин әле студент кына, тик шулай да атнага 12 дәрес укытып, 24 мең сум акча алам. Бер дәрес 40 минутка сузыла. Моннан тыш, репетиторлык белән дә шөгыльләнәм, – дип җавап бирде ул.

Ризәлә әле фәнгә дә вакыт таба. Мәктәп елларында фәнни конференцияләрдә катнашып үскән, мәктәптә «Эзләну» дигән фәнни түгәрәкнең президенты булган. Башта гаиләсенең, якташлары, Советлар Союзы Геройларының тарихын өйрәнсә, аннан туган як темасына күчкән. 10–11 сыйныфларда татар теле һәм әдәбиятыннан халыкара олимпиадада җиңү яулаган. КФУда Ризәлә «Татар теленең актуаль проблемалары» дип аталган студентлар фәнни түгәрәгенең старостасы вазыйфасын үти. Узган ел вузда «Иң яхшы академик төркем старостасы» номинациясендә җиңү яулаган. Шул ук вакытта фән белән кызыксынуын дәвам итәрә. Ел дәвамында 15ләп фәнни мәкалә яза.

– Фәндә төп эзләнүләрем инглиз һәм татар телләрен укыту методикасына бәйле. «Интерактив дәфтәр» дип аталган методик әсбап булдырып, балаларны грамматика, лексикага өйрәтәсем килде. Аны курс эшемне җитәкләүче укытучым тәкъдим итте. Андый интерактив дәфтәрләрне чит илләрдә репетиторлар тел өйрәтү өчен куллана. Кагыйдәләрне кызыклы итеп укытуга юнәлдерелгән технология бу, – ди Ризәлә.

Күптән түгел узган Фән көнендә уңышлары өчен бүләкләгәннәр Ризәләне.

– Фән ул – үсеш һәм эзләну. Мин аннан рәхәтлек кенә алам. Хәзерге вакытта өч бәйгегә әзерләнәм. Теләгән эшкә вакыт һәрчак табыла. Бу – үзеңнең үсешеңә вакыт табу дигән сүз. Бүген театрга барырга җыенам. Дуслар белән шугалакларга йөрибез. Бер-беребезнең авылларына кунакка йөрешәбез. Уку, эш дип йомылып ятарга ярамый, – ди Ризәлә Гыйләҗева.

Сәрия МИФТАХОВА

АЯУСЫЗ КАПКА

КАЗАНДА ЧАЛЛЫ ТЕАТРЫНЫҢ ГАСТРОЛЕ БУЛДЫ

Күпләр көткән иде һәм, ниһаять! Яңартылганнан соң Аяз Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрының Казанда беренче зур гастроле булып узды. Театр коллективы башкала тамашачысын 3 кич дәвамында сөендерде. Берсендә безгә дә булырга җай чыкты.

Чаллы театры Казан тамашачысына «Яшь йөрәкләр», «Капка» һәм «Болан» спектакльләрен тәкъдим итте. Без исә «Капка» спектаклен карап кайттык. Аны сәхнәгә язучы һәм театрның әдәби бүлек мөдире Айгөл Әхмәтгалиеваның шул исемдәге пьесасы буенча театрның сәнгать җитәкчесе Олег Кинҗәгулов куйган. Төп рольне театр артисты Рәзил Фәхертдинов башкара. Рәссам – Ләйсән Хәсәнова, композитор – Эмиль Әмиров.

Спектакльнең үзенә күчик. Вакыйгалар үткән һәм хәзерге заманда бара. Әсәрнең төп герое Касыйм үзенең уйланылмаган адымнары аркасында авылдан чыгып качарга мәҗбүр була һәм гомере буе Камчаткада яши. Хатыны Екатерина һәм улы Володя аның туган ягына, туган теленә битараф. Әнисенең хатлары – аны туган җире һәм туган теле белән бәйләп торган җеп. Тик соңыннан ул җеп тә өзелә... Гомер буе кимсенеп яшәгән Касыймның авылдан егетенә үч итеп кенә аның кәләшен урлап кайтуы да, кызның үлемендә үзен гаепле хис итүе дә, туган авылыннан качып китүе дә – яшәү мәгънәсен эзләү, бәхет эзләү. Ерак Камчаткада яшәп, гомер азагында туган туфрактан бәхиллек алырга кайтырга җыенган Касыймны ни көтә соң? Спектакль финалында аның язмышы билгесез булып кала. Ике ут арасында бәргәләнгән, тик үзен җиңә алмаган кешенең ачы язмышы чагыла бу билгесезлектә.

Спектакльдәге икенчел геройлар – битлектән. Тормышта бит вакыт узу белән кешеләрнең йөзе әкренләп онытыла бара. Касыйм өчен дә поездлары юлдашларның, авыл кешеләренең йөзләре хәтердән югала. Туган нигез белән бәйләнешне югалту. Режиссер аны әнә шундый алым белән күрсәткән.

Сәхнә бизәлеше, ут, декорацияләр дә үзенчәлекле. Алар артистларның халәтенә, борчуларына тәңгәл килә кебек. Әйтик, сәхнәдәге купфункцияле корылмалар Камчаткадагы тауларны да, туган як агачларын да хәтерләтә. Төп декорация – хатирәләр купере һәм утлы портал формасындагы капка. Касыймның гомере әнә шул хәтер капкасын ачып чыгарга йөрәге җитмичә үтә дә инде. Әлеге каршылыкны һәм төп геройның хисләрен туган авыл, диңгез, соры күк йөзе кадрлары, музыкаль бизәлеш тагын да көчәйтә.

Сценарий авторы Айгөл Әхмәтгалиева әйтүенчә, Казан тамашачысы спектакльне яратып, бик җылы кабул иткән.

– «Капка» башта хикәя булару язылган иде. Ул минем өчен – гомер капкасы. Бу дөньяда яшисең, соңыннан капканы ачып, мәңгелеккә күчәсең. Бөтен кылган гамәлләрең капканың бу ягында кала. Ә теге якка үзең белән нәрсә алып китәсең соң? Хикәядә менә шундый фәлсәфи сорауларга җавап эзләдем. Пьесада капка образы киңрәк мәгънә алды. Анда кешенең әчке дөньясына, туган тел, туган нигез мәсьәләләре, әти-әни, кешенең рухи кыйммәтләрне бәяли белүенә төп урын бирелде. Спектакльне сәхнәгә куйган режиссерга бик рәхмәтлемен. Олег шушы кин колачлы, бай материалны сәхнәгә тыгыз итеп, символлар ярдәмендә, бер төенгә төйнәп, тамашачыга җиткерде. Күп тамашачылар, автор, режиссер һәм артистларның уйнавы тандем була алган, дигән фикер әйтте. Сәхнәгә менгән спектакль өчен, бу – мөгаен, иң олы бәядер. Димәк, «Капка»да әйтергә теләгән фикеребезне җиткерә алганбыз.

Спектакльне Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев та караган.

– Без элеккечә спектакльләргә, табигый декорацияләргә ияләшкән бит инде. Монда яңача формаларда эшләүне күрдек. Артистларның уены шәп, режиссер зур тырышлык куйган. Тик спектакльнең кайбер җирләрен аңлап бетермәдем, шулкадәр кызу барды. Аны мин, бәлкем, шушы яшемдә булгач, авыррак кабул иткәнмендер. Аңлау бераз читенрәк булды. Шулай да мондый спектакльләр булуга бик шат мин. Төп геройны уйнаган егеткә шаккаттым. Күп кенә спектакльләрдә кайчакта бернәрсә дә аңлашылмый, ә монда һәр сүзе аңлашыла. Әйтик, гырылдау белән, усал итеп сөйләшәләр. Әшәке кешене, гадәттә, шулай күрсәтәләр бит инде. Андыйны мин кабул итә алмыйм. Бөтен театрда шундый чир бар. Әшәке кеше иң матур сөйләүче булырга тиеш ул, минемчә. Ул тыштан әйбәт, әчтән куркыныч була. Тулаем алганда, миңа спектакль бик ошады. Тәрбия мәсьәләсе, ата-ана, туган тел. Болар – бүген бик кирәкле темалар, – диде Миңгол Галиев.

«Татаркино» оешмасы директоры, продюсер Миләүшә Айтуганова фикеренчә, спектакль темасының мөһимлеге турында әйтеп тә торырга кирәк түгел.

– Темасы бик мөһим. Чөнки бездә бу темага спектакльләр күп түгел. Әмма куелышы буенча бернигә соравым бар. Төп геройга килгәндә, миңа бераз органика җитмәде. Аның урынында икенче бер кеше булырга тиеш иде, дип уйлыйм. Бәлки, башкаларга шушы актер ошагандыр. Режиссерның вакыйгаларны бүгенге көн белән аралаштыруы. Монысы, әлбәттә, яхшы һәм мөһим алым. Тагын бер әйбер: бөтен спектакль дәвамында геройлар битлекләрдә йөри. Мондый алым ни өчен кулланылган? Режиссерның нык уйланылган, нинди бер символик мәгънәгә ия булган атрибутыдыр ул, бәлки. Тик аны гади тамашачы аңламады. Мөгаен, аны ничектер аңлатырга кирәк иде. Айгөлнең мондый катлаулы темаларга алынуын хуплыйм. Сценарий ягыннан аны сәхнәгә яраклаштыру зур осталык таләп итә, – диде ул.

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӘСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ
Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5322 данә
Гомуми тираж – 15277 данә
Газетага сертификат бирелде
Заказ 225

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кулъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Кучерен бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).
16+